# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Тархан торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**25 ноябрь 2023 ел** **№1**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 25 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының протоколы төзелде:

«Сез, 2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан һәм гаилә әгъзасы махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гаиләләрдән тыш, Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тархан авылы  торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 750 сумга киметеп,  үзара салым кертү  һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Тархан авылындагы юлларны кардан чистарту буенча хезмәтләргә түләү (эшкә килешү буенча түләү, тракторчыга хезмәт хакын түләү, ягулык-майлау материалларын алу).

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 21 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 20.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА»  позициясе өчен –  20,  «КАРШЫ»  позициясе өчен тавыш бирүче юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә, **гражданнар җыены карар итте**:

1. Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тархан торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«Сез, 2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тархан авылы  торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 250 сумга киметеп,  үзара салым кертү  һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Тархан торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, карап тоту (Тархан авылындагы юлларны кардан чистарту; вак ташны сатып алу, ташу, Лесная, Заречная урамнарына вак ташны җәю, эшкә килешү буенча түләү, тракторчыга хезмәт хакын түләү)).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Тархан авылы, Лесная ур., 2 йорт; Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендынларында урнаштырырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тархан авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Тархан авыл җирлеге башлыгы Р.К.Галимҗанова